РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**исполнительный комитет**
**Большесалтыковского сельского поселения**
422831, Республика Татарстан,
Камско-Устьинский район,
с. Б.Салтыки, ул. 1 Мая, 26А
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**
422831, Татарстан Республикасы,
Кама Тамагы районы,Олы Салтык
авылы, 1 Май урамы, 26А
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«03» июля 2023 года** **№3**

**Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыелган урыннарны билгеләү һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы ассоциациясенең» 2023 елнын 26 апрелендэге №409 хаты нигезендэ, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Олы Салтык авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

ФАП территориясе;
Мэктэп территориясе;
Балалар бакчасы территориясе;
Парк территориясе;
Балалар мэйданчыклары территориясе;
Мэдэният йортлары территориялэре;
Ял зоналары территориялэре;
Мэчет территориясе.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Вафин Рамил Миннегази улын хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүче вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61 йорт, һәм шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан коненнэн үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М. Вафин